**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

(8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

# Татарстан Республикасы Я
# ңа Чишмә муниципаль районы Советы
# КАРАРЫ

**2017 елның «27» июненнән** **№ 27-140**

**«2016 елда «2014-2016 елларда Яңа Чишмә муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруның барышы һәм 2017 елга бурычлар турында»**

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча) Л. К.Исхакованың 2016 елда «2014-2016 елларда Яңа Чишмә муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруның барышы һәм 2017 елга бурычлары турында мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

## КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елда «2014-2016 елларда Яңа Чишмә муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруның барышы һәм 2017 елга бурычлар турында мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына:

- 2017-2020 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү буенча муниципаль программаны үтәү эшен активлаштырырга;
- муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыкларына резидентларны җәлеп итү буенча эш алып барырга;
- эшкуарлык эшчәнлегенең уңай тәҗрибәсен өйрәнү, гомумиләштерү һәм тарату буенча эш алып барырга

- Яңа Чишмә муниципаль районының тулаем территориаль продуктында кече һәм урта эшкуарлык субъектларының өлешен 2017 ел азагына 14,7% ка җиткерергә;

- кризиска каршы чаралар кысаларында бюджетка салым һәм салым булмаган керемнәр буенча даими мониторинг үткәрергә, салым органнары белән берлектә салымнарны вакытында түләүне оештыру буенча оператив чаралар күрергә;

- товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне, сатып алуның нәтиҗәлелеген арттырырга, мондый сатып алуларны гамәлгә ашыруның ачыклыгын һәм үтә күренмәлелеген тәэмин итәргә, мондый сатып алулар өлкәсендә коррупцияне булдырмаска һәм башка явызларча куллануга юл куймаска;

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага, милеккә бирү өчен муниципаль милек реестрын актуаль хәлдә тоту;

- хезмәт базарында квалификацияле эшче көчләр тәкъдим итүне һәм ихтыяҗның туры килүен тәэмин итү буенча чаралар комплексын гамәлгә ашырырга;

- хезмәт базарында даими мониторинг алып барырга һәм халыкның мәшгульлегенә булышлык итү өчен чаралар комплексы кабул итәргә;

3. ТР Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына:

- 2017 елның I яртыеллыгында кече һәм урта эшкуарлык субъектлары буенча мәгълүмат әзерләргә, шул исәптән хезмәт хакы һәм аның үсеше буенча күрелә торган чараларны анализларга.

4. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**